**КАРАР**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль район советы утырышы**
**карары**

**16 октября 2019 ел** **№ 220**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 28 декабрендәге, 23нче номерлы "Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 28 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 статьяда:

3 пунктка «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән өчен, бу мәгълүматларны бозмаган очракта түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчы вазыйфасыннан азат итү.;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан даими нигездә азат итү, вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә. Габидуллинга йөкләргә.

**Глава Камско-Устьинского**
**муниципального района,**
**председатель Совета**
**Камско-Устьинского**
**муниципального района** **Н.А. Вазыйхов**